Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы

Советы Карары

2020 елның 28 августы

317№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының вәкиллекле органы каршындагы Яшьләр парламенты турындагы Нигезләмәне раслау хакында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 27 пунктына, Әлки муниципаль районы Уставына таянып, яшьләрнең иҗтимагый, сәяси тормышта катнашуын тәэмин итү, яшьләрне районның социаль - икътисадый проблемаларын хәл итүгә җәлеп итү, дәүләт, муниципаль идарә һәм икътисад өлкәсендә алга таба эшләү өчен яшьләрне әзерләү һәм алга этәрү системасын булдыру, муниципаль хакимият органнарының кадрлар резервын формалаштыру, яшьләрдә иҗади гражданлык позициясен формалаштыру максатында Әлки муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының вәкиллекле органы каршындагы Яшьләр парламенты турында Нигезләмәне расларга.

2. Әлки муниципаль районы Советының 2015 елның 26 февралендәге «Әлки муниципаль районы Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы төзү турында»гы 104 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4.Карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы: А. Ф. Никошин

Расланган
Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районының
вәкиллекле органы тарафыннан
2020 елның 28 августы 317 №

## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының (муниципаль берәмлекнең) вәкиллекле органы каршындагы Яшьләр парламенты турында Нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлки муниципаль районы вәкаләтле орган каршындагы Яшьләр парламенты (алга таба – Яшьләр парламенты) яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законнар һәм норматив хокукый җайга салу өлкәсендә Әлки муниципаль районы вәкиллекле органы (алга таба - вәкиллекле орган) эшчәнлегенә ярдәм итү, яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү, яшьләр өчен законнар чыгару эшчәнлеге күнекмәләрен үзләштерү һәм Татарстан Республикасы яшьләренең Россия яшьләр парламентаризмы хәрәкәтендә катнашу өчен шартлар тудыру максатларында оештырыла.

2. Яшьләр парламенты вәкиллекле орган каршындагы киңәшмә һәм консультатив орган булып тора һәм үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмә һәм Яшьләр парламенты регламенты нигезендә иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

3. Яшьләр парламенты вәкиллекле орган вәкаләтләре вакытында формалаша.

### II. Яшьләр парламентының төп бурычлары

4. Яшьләр парламентының төп бурычлары булып тора:

1) муниципаль берәмлек территориясендә кулланыла торган яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив хокукый актлар (алга таба - норматив хокукый акт) эшләгәндә яшь гражданнарның инициативаларын күрсәтүдә ярдәм итү;

2) яшьләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өлкәсендә норматив хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

3) муниципаль берәмлекнең яшьләр хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив-хокукый актлары проектларын карауга әзерләү буенча вәкиллекле орган эшчәнлегендә катнашу;

4) яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив-хокукый актларга мониторинг ясауны гамәлгә ашыру буенча вәкиллекле орган эшчәнлегендә катнашу;

5) муниципаль берәмлек территориясендә яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыруга җәмәгать контролен гамәлгә ашыру;

6) яшьләр даирәсендә яшьләрнең хокукый культурасын һәм юридик грамоталылыгын күтәрүгә һәм актив гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлдерелгән агарту һәм аңлату эшләре үткәрү;

7) дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында яшь гражданнарның фикерен өйрәнү;

8) иҗтимагый әһәмиятле идеяләрне һәм инициативаларны алга этәрү һәм аларга ярдәм итү, тәҗрибә уртаклашу максатларында халыкара, гомумроссия, төбәкара, төбәк һәм җирле яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән даими хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

9) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты белән мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

10) Яшьләр парламентын булдыру максатларына туры килә торган һәм законнарга каршы килми торган башка мәсьәләләрне хәл итү.

## III. Яшьләр парламенты составы һәм оештыру тәртибе

5. Яшьләр парламенты әгъзасы буларак аларның вәкаләтләрен раслау көненә 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары Яшьләр парламенты әгъзалары була ала.

6.Яшьләр парламенты конкурс нигезендә муниципаль берәмлек яшьләрен тәкъдим итүче гражданнардан - вәкиллекле органдагы депутатлар саны белән бер үк санда төзелә;

7. Яшьләр парламентының әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән яшьләр вәкилләреннән төзелә торган персональ составы, Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган конкурс нәтиҗәләре буенча һәм әлеге Нигезләмәгә кушымта булып торучы Яшьләр парламентын формалаштыру буенча конкурс турындагы Нигезләмә нигезендә билгеләнә.

8.Яшьләр парламенты составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы тиешле муниципаль берәмлек яшьләрен тәкъдим итүче Яшьләр парламенты әгъзалары керә. Тиешле муниципаль берәмлек яшьләрен тәкъдим итүче яшьләрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты әгъзасына кабул итү конкурстан тыш гамәлгә ашырыла.

9. Яшьләр парламенты әгъзалары булып аларны яшьләр парламенты составына кабул итү көненә 35 яшькә кадәрге вәкиллекле орган депутатлары булырга мөмкин. Вәкиллекле орган депутатларын Яшьләр парламенты составына кабул итү конкурстан тыш гамәлгә ашырыла.

10. Яшьләр парламенты составына керү нияте турында гариза вәкиллекле орган депутаты тарафыннан Яшьләр парламенты Советына җибәрелә.

11. Яшьләр парламенты әгъзасы вәкиллекле органда фракциясе булган (алга таба - партия вәкиле) партия вәкиле булырга мөмкин. Партия вәкиле, вәкиллекле органга сайлауларда тиешле партия кандидатлары исемлеге составына кергән Яшьләр парламенты составына кертелгән көнгә 35 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданы булырга мөмкин. Яшьләр парламенты составына партия вәкилләрен кабул итү конкурстан тыш гамәлгә ашырыла.

12. Яшьләр парламенты составына партия вәкилен кабул итү партия вәкиленең шәхси гаризасы һәм вәкаләтле органда тиешле фракциянең документаль рәсмиләштерелгән карары нигезендә Яшьләр парламенты Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Яшьләр парламенты составына партиянең берәр вәкиле кабул ителә.

13.Алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты вәкиллекле органда конкурс буенча сайланган депутатлар санына тигез кеше санын, тиешле муниципаль берәмлек яшьләрен тәкъдим итүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты әгъзалары, вәкиллекле орган депутатлары һәм конкурстан тыш составка кертелгән партияләр вәкилләре санын исәпкә алып, Советы Яшьләр парламентының йомгаклау сан составын билгели һәм Яшьләр парламенты әгъзаларының вәкаләтләрен раслый. Беренче чакырылыш Яшьләр парламентының йомгаклау санын билгеләү һәм аның әгъзаларының вәкаләтләрен раслау муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы Советы тарафыннан, ә ул булмаганда – вәкиллекле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

14. Үз кандидатурасын күрсәткән Яшьләр парламенты әгъзасы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, әлеге Нигезләмәнең 6 пункты нигезендә, Яшьләр парламенты карары һәм тиешле исемлек буенча иң күп тавыш алган кандидат Яшьләр парламенты әгъзасы була. Күрсәтелгән карар Яшьләр парламенты Советы тарафыннан 10 көн дәвамында кабул ителә.

15. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктында күрсәтелгән исемлектә, иң күп тавыш алган башка кандидатлар булмаган очракта, яшьләр парламенты әгъзаларын сайлау әлеге Нигезләмә нигезендә конкурс уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

16. Конкурс нәтиҗәләре буенча Яшьләр парламенты әгъзалары саны әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән санга туры килмәсә, Яшьләр парламенты әгъзаларының җитмәгән санын сайлау әлеге Нигезләмә нигезендә конкурс үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

17. Яшьләр парламенты Регламентында каралган очракларда Яшьләр парламенты әгъзасы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

## IV. Яшьләр парламенты эшен оештыру

18. Яшьләр парламентының беренче утырышы алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты Советы тарафыннан (беренче чакырылыш Яшьләр парламентының беренче утырышы Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы советы тарафыннан, ә ул булмаганда - вәкиллекле орган тарафыннан) чакырыла.

19. Яшьләр парламентының беренче утырышын алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты рәисе (беренче чакырылыш Яшьләр парламентының беренче утырышын-муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы рәисе, ә ул булмаганда – вәкиллекле орган вәкиле)ачып җибәрә.

20. Беренче утырышта Яшьләр парламенты әгъзалары ачык тавыш бирү белән Яшьләр парламенты әгъзалары арасыннан рәисне, рәис урынбасарларын, җаваплы сәркатипне сайлыйлар, Яшьләр парламенты Советының санлы составын билгелиләр һәм аның әгъзаларын сайлыйлар, Яшьләр парламенты комиссияләрен төзиләр һәм аларның рәисләрен сайлыйлар. Яшьләр парламенты рәисенә кандидатлар үз эшчәнлек программаларын тәкъдим итәргә тиеш.

Яшьләр парламенты рәисе урынбасарларының саны Яшьләр парламенты рәисе тәкъдиме белән билгеләнә.

21. Яшьләр парламенты утырышы, әгәр анда Яшьләр парламенты әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы була.

22. Яшьләр парламенты үз эшчәнлеге юнәлешләре буенча эшче һәм эксперт төркемнәре төзергә, тәкъдимнәр эшләргә һәм кабул итәргә, аларны вәкиллекле органга һәм җирле үзидарә органнарына җибәрергә хокуклы.

23. Яшьләр парламенты карары, әгәр аның өчен Яшьләр парламентының сайланган әгъзаларының, шулай ук аның составына кертелгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентының тиешле муниципаль берәмлек яшьләренең, вәкиллекле орган депутатларының һәм партия вәкилләренең күпчелеге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

24. Яшьләр парламенты советын вәкаләтләре Яшьләр парламенты регламенты белән билгеләнә Яшьләр парламенты рәисе җитәкли.

25. Яшьләр парламенты Советы:

1) Яшьләр парламенты һәм аның комиссияләре эшен оештыра һәм координацияли;

2) Яшьләр парламенты регламентын эшли һәм аны Яшьләр парламенты раславына тәкъдим итә;

3) чираттагы елга Яшьләр парламентының эш планнарын эшли һәм аларны Яшьләр парламентына раслауга тәкъдим итә;

4) Яшьләр парламенты регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

26. Яшьләр парламенты комиссияләре эшне оештыралар һәм Яшьләр парламенты утырышларында карау өчен үз функцияләренә туры китереп рекомендация һәм карар проектларын әзерлиләр.

27. Яшьләр парламенты эшендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, Дәүләт Советы депутатлары, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары, шулай ук чакыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләре, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары вәкилләре, Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче сәяси партияләр һәм иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар катнаша ала.

Татарстан Республикасы вәкиллекле органының
______________________________________
(муниципаль берәмлекнең)
Яшьләр парламенты турындагы Нигезләмәгә
кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**(муниципаль берәмлек)**

# ВӘКАЛӘТЛЕ ОРГАН КАРШЫНДА ЯШЬЛӘР ПАРЛАМЕНТЫ ФОРМАЛАШТЫРУ БУЕНЧА БӘЙГЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Әлеге Нигезләмә Әлки муниципаль районының вәкиллекле органы каршындагы Яшьләр парламентын формалаштыру буенча бәйге үткәрүнең гомуми принципларын һәм тәртибен билгели (алга таба - конкурс).

2.Бәйге Әлки муниципаль районының вәкиллекле органы каршында Яшьләр парламенты (алга таба - Яшьләр парламенты) Әлки муниципаль районының вәкиллекле органында (алга таба - вәкиллекле орган) депутатлар санына тигез халык санында составын формалаштыру максатларында уздырыла.

## II. БӘЙГЕНЕ ОЕШТЫРУЧЫ

3. Бәйгене оештыру һәм үткәрүне оештыру комитеты (алга таба - Комитет) гамәлгә ашыра.

4.Комитет составы вәкиллекле орган вәкилләре, алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты (беренче чакырылыш Яшьләр парламентын - муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы вәкилләрен формалаштыру буенча бәйге үткәрелгәндә), яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең башкарма хакимияте органы арасыннан тигез нигездә төзелә.

5. Комитет составы, шул исәптән аның Рәисе, алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты карары белән раслана (беренче чакырылыш Яшьләр парламентын формалаштыру буенча бәйге үткәрү комитетына карата - вәкиллекле орган каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы карары белән, ә ул булмаганда – вәкиллекле орган тарафыннан). Комитет саны 3 кешедән дә ким була алмый.

6. Комитет:

1) Интернет челтәрендәге бәйгенең рәсми мәгълүмат ресурсы булган (алга таба-мәгълүмат сайты) http://molparlament.tatar сайтында бәйгедә катнашу өчен гаризалар кабул итә;

2)бәйгедә катнашучылар белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

3) бәйгегәйомгак ясый;

4) әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

7. Комитет утырышы, әгәр анда Комитет раслаган әгъзаларның яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

8. Комитет карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Комитет рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

9. Комитет вәкаләтләре Яшьләр парламентының йомгаклау составы расланганнан соң туктатыла.

## III. БӘЙГЕНЕ ҮТКӘРҮ ШАРТЛАРЫ ҺӘМ ТӘРТИБЕ

10. Бәйгене игълан итү, шул исәптән аны үткәрү вакыты турында карар алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты тарафыннан кабул ителә. Беренче чакырылыш Яшьләр парламентын формалаштыру буенча бәйге игълан итү, шул исәптән конкурсны үткәрү вакыты турындагы карар вәкиллекле орган каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы, ә ул булмаганда – вәкиллекле орган тарафыннан кабул ителә.

11. Бәйгене игълан итү турында карар, бәйгене үткәрү шартлары һәм сроклары турында мәгълүмат Комитет тарафыннан бәйгене мәгълүмати сайтта игълан итү турында Карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә урнаштырыла, шулай ук Интернет челтәрендәге вәкиллекле органның рәсми сайтында урнаштыру өчен җибәрелә.

12. Яшьләр парламенты әгъзаларына кандидатлар Яшьләр парламенты турындагы Нигезләмәнең 5 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

Хөкем ителгәнлекне бетермәгәнлеге (суд хөкемен тулысынча үтәп бетермәгәнлеге) булган, шулай ук административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.3 һәм 20.29 статьяларында каралган административ хокук бозулар кылган өчен административ җаваплылыкка тартылган (җәлеп ителгән) затлар Яшьләр парламенты әгъзаларына кандидатлар сыйфатында катнашырга хокуклы түгел.

13. Бәйге этаплап үткәрелә.

14. Бәйгенең беренче этабы бәйгедә катнашырга теләк белдергән гражданнар тарафыннан гаризалар кабул итүне үз эченә ала.

15. Гаризалар электрон рәвештә мәгълүмати сайтка тапшырыла;

16. Гариза составына керә:

1) алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты карары белән билгеләнгән форма буенча шәхси гариза (беренче чакырылыш Яшьләр парламенты составын формалаштырганда - вәкаләтле орган каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы карары белән, ә ул булмаганда – вәкиллекле орган тарафыннан);

2) алдагы чакырылыш Яшьләр парламенты карары белән билгеләнгән форма буенча кандидат тутырган анкета (беренче чакырылыш Яшьләр парламенты составын формалаштырганда - вәкиллекле орган каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы карары белән, ә ул булмаганда – вәкиллекле орган тарафыннан.). Анкетада бәйгедә катнашу өчен үз кандидатурасын тәкъдим иткән гражданның әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәүне билгеләргә мөмкинлек бирүче белешмәләр мәҗбүри рәвештә күрсәтелергә тиеш;

3) гражданның шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы.

17. Бәйгедә катнашу өчен гражданнарның гаризалары турыдан-туры Комитет тарафыннан кабул ителә.

18. Тапшырылган (җибәрелгән) гаризалар Комитет тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Комитет гариза кабул итү һәм бәйгенең киләсе этабында катнашу өчен рөхсәт бирү турында карар кабул итә. Киләсе этапта катнашуга рөхсәт ителгән Яшьләр парламенты әгъзалыгына кандидат статусын ала (алга таба - кандидат).

19. Бәйгенең икенче этабы яшьләрне Яшьләр парламенты составын формалаштыру буенча бәйге буенча тавыш бирүгә җәлеп итү буенча кандидатлар катнашында чаралар үткәрүне үз эченә ала.

20. Комитет кандидатлар катнашында чаралар исемлеген формалаштыра. Һәр кандидат кандидат мөстәкыйль рәвештә билгели торган бер чарада катнашырга тиеш. Чарада кандидат катнашмаган очракта, Комитет аны бәйгедә катнашудан читләштерә.

Кандидат законнарга каршы килми торган чараларны мөстәкыйль рәвештә үткәрергә хокуклы.

21. Өченче этап кандидатлар өчен тавыш бирү үткәрүдән гыйбарәт.

22. Кандидатлар өчен тавыш бирү Интернет челтәре https://open.tatarstan.ru/polls (алга таба-тавыш бирү сайты) сайтында башкарыла.

23. Тавыш бирүдә Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче 14 яшьтән 35 яшькә

кадәрле Россия Федерациясе гражданнары (алга таба - тавыш бирүдә катнашучы)катнаша ала.

24. Тавыш бирүдә катнашучы кандидатларның чикләнмәгән саны өчен тавыш бирергә хокуклы. Шул ук вакытта муниципаль берәмлектән кандидат өчен бары тик Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче тавыш бирүдә катнашучы гына тавыш бирергә хокуклы.

25. Тавыш бирүдә катнашучы кандидатлар өчен бер генә тапкыр тавыш бирергә хокуклы.

26. Дүртенче этап бәйгенең тавыш бирү нәтиҗәләрен игълан итү һәм бастыруны үз эченә ала.

27. Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлегендә иң күп тавыш җыйган кандидатлар бәйге җиңүчеләре дип таныла.

28. Тавыш бирү нәтиҗәләре http://molparlament.tatar мәгълүмати сайтында урнаштырыла.

29. Бәйгене үткәрү вакыты, шул исәптән бәйгенең һәр этабы вакыты, бәйгене үткәрү турындагы карарда билгеләнә.